**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**2022 ел, 20 апрель** **№75**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Дәвеш авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Дәвеш авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 7 июнендәге 147 номерлы карары белән расланган Татарстан республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Дәвеш авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне» дигән 3.7 бүлегенең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 84 статьясындагы 1 өлеше нигезендә торак пунктларның чикләрен билгеләү, үзгәртү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга (бастырып чыгарырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Дәвеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Дәвеш авыл җирлеге Башлыгы** **Т. Т. Хөсәенов**